КЛАРА БУЛАТОВА

МАРС КИТАБЫ

КЛАРА БУЛАТОВА

МАРС КИТАБЫ

Казан ○ Татарстан китап нәшрияты ○ 1982

МАРТ БАШЫНДА

Кара карга төшкән карга,
ак сызыктан —
Кыш ягыннан яз ягына
сикереп чыккан.
Чыбыкларда чыпчыклар да
сикерешәләр,
Яз килде дип чыркылдаша,
сөенешәләр.
Күгәрченнәр гөрелдәшә
гөлдер-гөлдер!
Март башланды, карлар эрер,
карлар эрер.
Ә урманда бар да яңа
кызык тапкан:
Өнендәге аю сыңар
күзен ачкан,
Бер ботактан бер ботакка
күчә-күчә
Тиен бии, тукран җырлап
кайры тишә.
Куяннар да бәйрәм ясап
алмакчылар,
Кышын кигән ак туннарын
салмакчылар.
Март башланды. Җир уяна,
көн яңара,
Кыш ягыннан яз ягына
очып бара!

РӘХӘТ ЧАК

Җып-җылы апрель көне,
Талларда песи-бөре,
Басулар әле кара.
Уң кулда — әни кулы,
Сул кулда — әти кулы,
Марс уртадан бара.
Ачылган бакча юлы,
Әти кулы нык, олы,
Әни кулы йоп-йомшак,
Яннан гөрләвек ага,
Марс уртадан бара,
Әйбәт,
рәхәт, яхшы чак.

СӨЕНЕЧ

Сыерчык кайтты безгә
Бергә җәй җәйләр өчен,
Өзеп-өзеп сайрар өчен,
Бакчаны ямьләр өчен.
Тагын чәберчек белән
Бүрекле песнәк килгән.
Чуар тукран да карый
Түгәрәк матур өйдән.
Уткойрык бар, чебенче.
Зур Марсның сөенече:
Кайткан бит кошкайлары,
Канатлы дускайлары.



УРМАНДА

«Җиләк җыям, как коям
Әниемә бүләккә.
Монда җиләк күп икән,
Аю, бүре юк микән».
Марс килгән урманга
Қура җиләк җыярга.
Җыйсын әле күп итеп,
Қакка җитәрлек итеп.
«Җиләк җыям, как коям
Әбиемә бүләк дип.
Әби тәмләп чәй эчәр,
«Улым җыйган җиләк»,—
дип.

ШУНДЫЙ КӨН

Тәрәзәдән өйгә көн кергән,
Бүләк итеп кояш китергән.
Бөтен кеше эштә чакта, ди,
Тор, тор, Марс!
Йоклап ятма! — ди.
Бәрәңгеләр үсеп җиткән, ди,
Помидорлар пешкән күптән, ди,
Бакчага чык, тизрәк җыеш, ди,
Әбиеңә, әйдә, булыш, ди.
Сикереп торды Марс, киенде
Һәм бакчага чыгып йөгерде.
Бүген безгә шундый көн
килгән,—
Қояш белән Хезмәт китергән.

ЗООПАРКТА

Марс дәшкәч, читлектәге
Кара маймыл баласы
Чыгам дип сикергән иде,
Тартып алды анасы.
Ачуланып үз телендә
Нидер әйтте, ахырда
Сүзе генә үтмәс дипме,
Сугып куйды артына.

Күрәсең, ул да улына
«Ярамый!» — дип әйтәдер,
Тел белән дә, кул белән дә
Тәртипкә өйрәтәдер.
Булгалый ул,
тыңламыйча
Маймылланып йөргәндә,
Кайчак шулай әнисеннән
Марска да эләгә.

ЯРЫШУ

Юл буенда чәчкәләр,
Су буенда бәбкәләр.
Яр читендә тирәкләр,
Су өстендә үрдәкләр.
Шунда безнең Марс та
Үрдәк белән ярыша.
Төрле яктан ярыша,
Ике яктан калыша.
Үрдәк суда да йөзә,
Үрдәк оча да белә.
Марс аның шикелле
Оча белми шул әле.
Суларда да үрдәк кебек
Оста йөзми шул әле.
Яр буенда дигәндә,
Җирдә җәяү йөргәндә,
Икесе гел бер алар —
Алпан-тилпән баралар.

ИПТӘШ

Илдарның бар сеңлесе,
Ленарның бар энесе.
Марс кына берүзе,—
Ялгыз әллә нишлисе.
Матур песи таптылар,
Өйгә алып кайттылар.
Әмма ни хәл итәсе:
Куркак булды иптәше.
Тик утыра почмакта,
Чыгып йөрми йортка ул.
Барыннан да бигрәк
Тычканнардан курка ул.

ӘНИЕМНЕҢ КЫЗЫ ЮК БИТ

Әниемнең кызы юк бит,
Мин әнигә бер генә.
Кызы да юк, эше дә күп
Әнинең берүзенә.
Әниемнең кызы юк шул,
Мин булышам әнигә.
Аш пешерәм, җыештырам,
Кер юышам әнигә.
Магазиннан сөт апкайтам,
Ипигә дә йөгерәм.
Әниемнең кызы юк та —
Малае бар бер дигән.

УНГА КАДӘР

Марсның бармаклары —
Санагыч таяклары.
Бер турайта, бер бөгә,
Унга кадәр сан белә.
Әти белән әни, ди,
Бабай белән әби, ди,
Үзем, абый һәм апа,
Боларга кушкан чакта
Бозау белән песи, ди,
Алай да җитешми, ди,
Этемне дә син куш, ди,
Унынчысы — Актүш, ди.

КЫЗЫК ИНДЕ БУ БАБАЙ

Көн кояшлы булган чакта
Марс йөри сөенеп.
Әллә нигә шундый чакта
Бабай йөри көенеп.
Бүген, әнә, яңгыр ява,
Ишек алды чылана,
Бөтен урам пычрана бит!
Бабай шуңа куана.
Яңгыр яугач, җир пычрана,
(Бабай шуны уйламый.)
Җир пычрангач, өс буяла,
Әни тышка чыгармый.

Бабай әйтә:
— Кара,— ди,—
Җиргә бодай ява,— ди.
Бодай түгел, яңгыр ява!
Әллә күрми, әллә белми,
Әллә юри алдалый.
— Яңгыр күмәч үстерә,—
ди,—
Сиңа коймак китерә.
Коймакны да, күмәчне дә
Аны әни пешерә!
Кызык инде бу бабай,
Уйнап сөйли ник алай?
Аны гына белмәскә,
Марс инде өч яшьтә!

БАКЧАДА

Бабайның бакчасы бар,
Бакчада алмасы бар.
Алмагачның алмаларын
Үрелеп аласы бар.
Уң кулын суза Марс,
Сул кулын суза Марс,
Аяк очларына басып
Алмакчы була Марс.
Ничек кенә аласы соң,
Нинди җаен табасы?
Рәхәтләнеп үзде Марс
Күтәргәчтен бабасы.



МАРС — УҢГАН ЕГЕТ УЛ

Әни әйтте:
— Бар,— диде,—
Улым, шикәр ал,— диде,—
Әткәң дә кайтып килер,
Чәй кайнаганчы өлгер!
Еракмыни ул кибет!
Марс — бик уңган егет,
Берлек тотып кулына
Чапты-китте юлына.
Килеп керде кибеткә,
Күзе төште шүрлеккә.
Уенчыклар куйганнар:
Озын колак куяннар,
Әллә нинди курчаклар,
Тояклары куш атлар,
Йөнтәс тәпи аю да —
Барысы да бар монда.
Марс шуңа юлыкты,
Ник килгәнен онытты.
Каршысында — кибетнең
Сатучысы Нуретдин.
— Һай матурлар бигрәк,—
ди,—
Сиңа кайсы кирәк? — ди.
Марска ошый бары да,—
Белми кайсын алырга.
Алыр иде барчасын —
Бер генә сум акчасы.
— Әнә, теге аюны
Күрсәт әле, абый,— ди.
Бер генә сум тора бит,
Аны алып була бит!
Еракмыни ул кибет,
Марс — бик уңган егет.
Бер басасын биш атлап
Кайтты аю кочаклап.



ЯНГЫН

Марс:
— Әти, кара,— ди,—
Кояш янып бара! — ди.—
Әти, сүндер! Янып бетсә,
Җир кояшсыз кала,— ди.

СОЛДАТЛАР

Бабай да солдат булган,
Әти дә солдат булган.
Зур абый да солдат булып
Ил чикләрендә торган...
Кече абый солдат булып
Китте быел яз гына,
Мин үзем дә солдат булам,
Үсим генә аз гына.

ТЕЛ БЕЛМӘҮ

Ял көнендә Марсларга
Әнәс абыйсы килә.
Марсның абый бүреген
Киеп карыйсы килә.
Бүрегенә йолдыз таккан
Солдат абый, дәү абый.
Әмма үзе зур булса да
Ни әйткәнне аңламый.
Марс: «Бир!» — ди, теге бирми,
Үзен ала кулына.
Чөнки Марс: «Мә!» — дип
сөйли
Бир диясе урынга.



МАРС КЫНА

Урам тулып, әрле-бирле
Бик күп кеше йөргәнгә
Марс кына гаҗәпләнә,
Гаҗәпләнми берәү дә.
Чыбыкларны чыжылдатып
Троллейбус үтеп китә.
Берәүнең дә исе китми,
Марсның исе китә.
Күтәртү кранын күрсә,
«Бу ни бу?» — дип баш
ватып
Берәү дә шаккатмаганда,
Марс тора шаккатып.
«Бу нәрсә? Ник?
Ни өчен?» — дип
Марс йөри урамда,
Таңга калып һичбер кеше
Таң калмаган дөньяга.

ӘНИ — ЕГЕТ

Әти дә эштән кайтты,
Әни дә эштән кайтты.
Әни кухняга чапты,
Әти диванга ятты.
Әти әйтә: «Мин ач,— ди,—
Кайчан була бу аш?» — ди.
Әни әйтә: «Үзең дә
Булыш алай булгач!» — ди.
Әти әйтә: «Булмый,— ди,—
Анысы кулдан килми,— ди.—
Хатын түгел, мин — ир,—
ди,—
Аш пешерә белмим»,— ди.
Әни аш та пешерә,
Эшли бөтен эшне дә.
«Җитмеш төрле һөнәр аз,—
ди,—
Егет булган кешегә».
Әни — егет,
ул белә бит
Әти белмәс эшне дә.



ӘЛЛӘ КАЙСЫН ТЫҢЛАСЫ

Әби баса камырын,
Бабай итен тапаша.
Марс инде шул тирәдә
Булышам дип маташа.
Бабай әйтә: «Һай рәхмәт!
Яса, улым, яса,— ди,—
Пилмәнебез тәмле булыр,
Үзең эшләп аша!» — ди.
Әби җәя камырын,
Бабай итен салыша.
Марс та бик ясар иде —
Камыр кулга ябыша.
Әби әйтә: «Бәбкәем,
Син бәләкәй шул әле,
Камырымны бозасың бит,
Карап кына тор әле!»
Әллә эшләп ашасы,
Әллә карап торасы.
Берсе куша, берсе тыя,
Әллә кайсын тыңласы.

УРАМДА

Марс — газон янында,
«Яшел дөнья» сагында.
Яшел тасма бәләктә,
Олыларны өйрәтә.
— Үлән таптап йөрмәгез,
Газоннарга кермәгез.
Тротуардан атлагыз,
Яшеллекне саклагыз.

АТЛАР ЯСЫЙ МАРС

Атлар ясый Марс.
Атлары
Кайсы зәңгәр,
кайсы сап-сары.
Арада бар кызыл, аклары,
Тик нигәдер боек атлары.
Бар чуары, көрән, карасы.
Атлар көтә иде бабасы.
Нәдер бабай үлде көз көне,
Шуңа боек атлар төркеме.

БУРАН

Тышта буран котыра,
Әти өйдә утыра.
Машинасы тик тора.
— Чыга алмый торам,—
ди,—
Тышта кара буран,— ди.
Әти белми:
буран ул
Қара булмый,
ак була!

ЙОМГАКЛАР

Қапка төбендә
Ул нинди йомгак?
Бу — Марс икән,
Һич туймый уйнап.
Ауный, тәгәри,
Ничек арымый?
Янында аунап
Йөри Шаригы.
Йөриләр шунда
Қөртләргә кереп,
Гел ике йомгак
Тәгәри кебек.

КАЙГЫ

Қайгысы бик олы
Кечкенә Марсның,
«Қыш бабай килмәс,— ди,—
Қары юк бит тышның.
Юлда кар булмагач,
Чанасы шумас,— ди.—
Қыш бабай килмәгәч,
Яңа ел булмас»,— ди.
Ә иртән торуга
Бөтен җир агарды,
Қар яуган!
Марсның
Қайгысы таралды.

10 тиен

Художнигы С. КУЛЬБАКА

Булатова Клара Газизовна

КНИГА МАРСА

Стихи

(на татарском языке)

Редакторы *С. Сибгатуллина.* Художество редакторы *Г. Трифонова.* Техник редакторы *Л. Таук.* Корректоры *Р. Хамидуллина.*

ИБ № 262[illegible]

Наборга бирелде 30.04.82. Басарга кул куелды 28.10.82. Формат 70×90¹/₁₆. 100 гр. обложка кагазе. Гарнитура литературная. Печать офсетная. Учетн.-изд. табагы 2,3. Якынча басма табагы 1,8. Усл. кр. отт. 4,4. Заказ У-306. Тираж 20 000. Бәясе 10 тиен. Татарстан китап нәшрияты, Казан, Бауман ур., 19. Татарское книжное издательство. Казань, ул. Баумана, 19. Татарстан АССР нәшрият, полиграфия һәм китап сәүдәсе эшләре дәүләт комитетының Камил Якуб исемендәге полиграфия комбинаты. Казан, Бауман ур., 19.

ББК 84.3(Тат)
Б75

Б $\frac{70801-276}{М132(03)-83}$ 144—83

© Татарстан китап нәшрияты, 1983.